ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

20.12.2024 г.Казань № 722-205/кс-2024

Чистай муниципаль районының «Чистай җылылык челтәрләре предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга 2025 елга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 20.12.2024 ел, №37-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы Чистай муниципаль районының «Чистай җылылык челтәрләре предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте (алга таба – «Чистай җылылык челтәрләре предприятиесе» ААҖ) тарафыннан җибәрелә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга әлеге карар кушымтасы нигезендә календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Чистай җылылык челтәрләре предприятиесе» ААҖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В.Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
20.12.2024 № 722-205/кс-2024
карарына кушымта

Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Чистай җылылык челтәрләре предприятиесе» ААҖ тарафыннан кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга 2025 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Кайнар су белән тәэмин итүче оешма, муниципаль берәмлек исеме | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тариф (бер компонентлы), сум/куб.м | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасы | | | | | | | |
| | | изоляцияләнгән торбалар белән | | изоляцияләнмәгән торбалар белән | | изоляцияләнгән торбалар белән | | изоляцияләнмәгән торбалар белән | |
| | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | |
| | | әйе | юк | әйе | юк | әйе | юк | әйе | юк |
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | | | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | | | |
| | Чистай муниципаль районы | | | | | | | | |
| 1 | "Чистай җылылык челтәрләре предприятиесе" ААҖ | | | | | | | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | 219,00 | 205,13 | 235,66 | 221,22 | 255,01 | 238,72 | 274,55 | 257,62 |
| 1.2 | башка кулланучылар (тарифлар НДС исәбеннән башка күрсәтелгән) | 182,50 | 170,94 | 196,38 | 184,35 | 212,51 | 198,93 | 228,79 | 214,68 |

* Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын үтәү максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге